# Басулар киңлегендә

*(«Кама» колхозы тормышыннан. «Яңа Кама» газетасы, 1978 ел, 19 апрель)*

Яңа Кама

1918 елдан бирле чыга

№ 63 (6248)

Чәршәмбе 19 апрель 1978 ел

Бәясе 2 тиен

КПССның АЛАБУГА ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ, ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ШӘҺӘР һәм РАЙОН СОВЕТЛАРЫ ОРГАНЫ

## БАСУЛАР киңлегендә

«Кама» колхозы правлениесендә дежурныйдан тыңлап ... килүе дә күренде.

— Барысы да җирдә, — диде дежурный безнең сорауга.

Берничә йөз метр читтәрәк, тугайларының җылысын уздырырга тырышкандай, культуралы көтүлекләр җирендә тырмалау агрегатының гөрелтесе ишетелә.

— 14 апрельдә дым каплатуга керештем, — ди комсомолец Илдар Закиров. — Көнгә нормада каралган 42 гектар урынына 60 гектардан артык җир эшкәртәм. Миңа прицепщик Илфат Миңнебаев булыша.

Илдарның кәефе күтәренке. Ул яз җитүгә, чын эш башлануга куанып бетә алмый. Башкача булырга да мөмкин түгел: бу — аның механизатор тормышында беренче чәчү осте. Аңа кадәр И. Закиров шофер иде, хәзер аның күптәннән тракторда эшләп карыйсы килде. Менә егетнең хыялы тормышка ашты...

Юлның теге ягында күпьеллык үлән участогында арба тагылган көпчәкле трактор хәрәкәтләнә, аның янында кешеләр нидер кылалар. Пенсионерлар люцерняны, кылчыксыз киндерлекны (костер безостый) кулдан чәчәләр. Аны Рәшит Гыйльфанов шунда ук тырмалый.

Берничә йөз метр читтәрәк коммунист Н. А. Данилов туңга сөрелгән җирләрне тырмалый.

— Өч көндә нибары 50 гектарда дым каплаттым, — ди Николай Андреевич. — Чөнки туфрак юеш иде, шуның өстенә басуда баганалар күп, эшләү кыен.

Аның ДТ-75 е яңадан кара җир буйлап юнәлә, аның артыннан тигез полоса сузыла.

Без правлениегә әйләнеп кайтабыз. Аның председателе Б. В. Әхмеров шунда иде.

— Әйе, язгы кыр эшләре башланды, — дип кабатлады ул. — Культуралы көтүлекләрне, күпьеллык үләннәрне һәм туңга сөрелгән җирләрне тырмалыйбыз, күпьеллык үләнне өстәп чәчәбез. Бәзәкә бригадасында культивацияләүгә һәм чәчүгә чыктылар.

Машина яңадан Ык Тамагына юл тота. Посадкалар, чокырлар күзгә чалынып кала.

Югары урдан тирә-яктагы һәр нәрсә: Ык Тамагы авылы йортлары һәм ташландык чиркәү, мул сулы Кама елгасы, кырлар һәм урманнар, алар буйлап акрын гына баручы тырмалау агрегатлары — барысы да уч төбендәге кебек күренеп тора. Биредә арпа чәчеләчәк, ә хәзергә ДТ-75 тә Нурияхмәт Әзин һәм Т-4 тә Нигъмәтҗан Гыйлаҗев дым каплаталар. Алар артыннан Рифкать Гыйлаҗевның культивацияләү агрегаты килә.

— Бүген эшкә керештем, — ди Рифкать, — хәзергә барысы да әйбәт бара.

Мәһабәт «Кама» елгасыннан боз кисәкләре һәм баржалалар килә, аның яр буйларында колхоз атлары йөри, шулар янында Габдулла Гәрәев туңга сөрелгән җирләрне тырмалый. Ул чәчүне хезмәттә зур уңышлар белән башлады — нормадагы 42 гектар урынына көн саен 60 гектарда дым каплата. Шуннан ерак түгел Нургали Ясәвиевның өч чәчкечле агрегаты басуларны иңли. Аның чәчүчеләре — Сәетвәли Галиев белән Муллануур Гыйззәтуллин. Алар беренче көн солы чәчәләр, шуңа күрә биредә ярдәмчеләр шактый күп җыелган. Шунда ук хуҗалык агрономы З. Тарасова, трактор бригадасы бригадиры М. Халиков һәм учетчик Ш. Миңнәхметов интәшләр бар.

— Солыны гектарына 2,2 центнер исәбеннән чәчәбез, — ди комплекслы бригада бригадиры М. Фәссахов. — Әлегә тик торулар юк. Монда М. Гайнуллинның һәм Х. Зәйнуллинның ашлык төягечләре дежур тора. Ягулыкны бензовозларда М. Сәлимуллин белән М. Таҗиев ташый. Эш карышмый.

Чәчү агрегаты басу читенә килә, ящикларга тоныл сары төстәге солы орлыгы агыла. Чәчкечләр яңадан басуга юнәләләр. «Кама» колхозында чәчү башланды.

**Л. ТОМИЛОВА.**



**Рәсемдә: тракторчы Нургали ЯСӘВИЕВ белән агроном Зоя ТАРАСОВА: чәчү агрегаты эш вакытында.**

И. НАУМОВЕЦ фотосы.

«Кама» колхозы правлениесендә, дежурныйдан башка, бер җан иясе дә юк.

-Барысы да кырда,- ди дежурный безнең сорауга.

Берничә йөз метр читтәрәк, тургайларның җырын уздырырга тырышкандай, культуралы көтүлекләр җирендә тырмалау агрегатының гөрелтесе ишетелә.

-14 апрельдә дым капларга керештем,- ди комсомолец Илдар Закиров. –Көнгә нормада каралган 40 гектар урынына 60 гектардан артык җир эшкәртәм. Миңа прицепщик Илфат Миңлебаев булыша.

Илдарның кәефе күтәренке, ул яз җитүгә, эш башлануга куанып бетә алмый. Башкача булырга да мөмкин түгел. Бу яшь механизаторның тормышында беренче чәчү өсте. Аңа кадәр И.Закиров шофер иде, ләкин аның күптәннән тракторда эшләп карыйсы килде. Менә егетнең хыялы тормышка ашты.

Юлның теге ягында күпъеллык үлән участогында  арба тагылган көпчәкле трактор хәрәкәтләнә, аның янында кешеләр дә мәж киләләр. Пенсионерлар люцернаны, костер безостыйны кулдан өстәп чәчәләр. Аны Рәшит Гыйлфанов шунда ук тырмалый.

Берничә йөз метр читтәрәк коммунист Н.А.Данилов туңга сөрелгән җирләрне тырмалый. -Өч көндә нибары 50 гектарда дым каплаттым,-ди Николай Андреевич. –Чөнки туфрак юеш иде, шуның өстенә басуда баганалар күп, эшләү кыен.

Аның ДТ-75 е яңадан кара җир буйлап юнәлә, аның артыннан тигез полоса сузыла.

Без правлениегә әйләнеп кайтабыз. Аның председателе Б.В.Ахмеров шунда иде.

-Әйе, язгы кыр эшләре башланды,-дип кабатлады ул. –Культуралы көтүлекләрне, күпъеллык үләннәрне һәм туңга сөрелгән җирләрне тырмалыйбыз, күпъеллык үләннәрне өстәп чәчәбез. Бәзәкә бригадасында культивацияләүгә һәм чәчүгә чыктылар.

Машина яңадан Ык Тамагына юл тота. Посадкалар, чокырлар күзгә чалынып кала.

Югары үрдән тирә-яктагы һәр нәрсә: Ык Тамагы  авылы йортлары һәм ташландык чиркәү, мул сулы Кама елгасы, кырлар һәм урманнар, алар буйлап акрын гына баручы тырмалау агрегатлары- барысы да уч төбендәге кебек күренеп тора. Биредә арпа чәчеләчәк, ә хәзергә ДТ-75 тә Нуриәхмәт Азин һәм

Т-4 тә Нигъмәтҗан Гыйлаҗев дым каплаталар. Алар артыннан Рифкать Гыйлаҗевның культивацияләү агрегаты килә.

-Бүген эшкә керештем,-ди Рифкать,-хәзергә барысы да әйбәт бара.

Мәһабәт Кама елгасыннан боз кисәкләре һәм баржалар килә, аның яр буйларында колхоз атлары йөри, шулар янында Габдулла Гәрәев туңга сөрелгән җирләрне тырмалый. Ул чәчүне хезмәттә зур уңышлар белән башлады- нормадагы 40 гектар урынына көн саен 60 гектарда дым каплата. Шуннан ерак түгел Нургали Ясәвиевның өч чәчкечле агрегаты басуларны иңли. Аның чәчүчеләре- Сәетгәли Гәлиев белән Мулланур Гыйззатуллин. Алар беренче көн солы чәчәләр, шуңа күрә бирeдә ярдәмчеләр шактый күп җыелган. Шунда ук хуҗалыкның агрономы З.Тарасова, трактор бригадасы бригадиры М.Халиков һәм учетчик Ш.Миңнәхметов иптәшләр бар.

-Солыны гектарына 2,2 центнер исәбеннән чәчәбез,-ди комплекслы бригада бригадиры М.Фәссахов. –Әлегә тик торулар юк. Монда М.Гайнуллинның һәм Х.Зәйнуллинның ашлык төягечләре дежур тора. Ягулыкны бензовозларда М.Сәлимуллин белән М.Таҗиев ташый.

Чәчү агрегаты басу читенә килә, ящикларга тонык сары төстәге солы орлыгы агыла. Чәчкечләр яңадан басуга юнәләләр. «Кама» колхозында чәчү башланды.

*Л.Томилова*